НӘТИҖӘЛЕ СӘФӘР

Рөстәм Миңнеханов «Иннопром – 2022» халыкара сәнәгать күргәзмәсендә катнашты

> 2

МИЛЛИ МӘСЬӘЛӘ

Һәр милләткә тигез шартлар тудыру өчен тагын ниләр эшләп була?

> 3

ТАРИХИ ҖИР

Алабугада туристларны ничек җәлеп итәләр?

> 3

БӘЙРӘМ КАЙТАВАЗЫ

Бөтенлегебез дә, көчебез дә – төрлелектә

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 94 (28867) | Сишәмбе | 5 июль | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Зөһрә САДЫЙКОВА

ӘРСЕЗ КУНАК

Кайдадыр тавыкларны буып чыкканнар, кайдадыр куяннарга һөҗүм иткәннәр. Республиканың төрле районнарыннан килеп ирешкән шундый эчтәлектәге хәбәрләрне әледән-әле ишетергә туры килә. Авылларга килүче чакырылмаган кунаклар кемнәр алар? Һәм аларга каршы ничек көрәшергә?

vk.com

Соңгы көннәрдә интернетта кара төстәге, ак тәпиле һәм ак борынлы җәнлекләр төшерелгән видеолар пәйда булды. Белгечләр аның кыргый әрлән, карабаш булуын әйтә. Ул яшелчә бакчасына зур зыян сала икән. Бигрәк тә кишер, бәрәңге белән сыйланырга ярата, ди. Җирне казып, теләсә кая зур һәм күп тишекләр ясый. Әлеге җәнлекләрне су буенда урнашкан авылларда аеруча күп очратырга мөмкин.

Арчада яшәүче Ильяс Фәттаховларның бакчаларында да кыргый әрлән еш кунак була икән.

– Казансу янәшәдә генә булгач, кыргый әрлән элек тә бар иде, хәзер дә еш очрый. Аңа аптырыйсы юк. Безнең тирәлек өчен гадәти күренеш ул, – ди Ильяс Фәттахов. – Бервакыт Шәмсенур апа колхоздан ике капчык борчак алган иде. Аны зур бер савытка бушатып куйганнар. Күпмедер вакыт узгач, чыгып карасалар, борчактан җилләр искән. Башта күсе ташып бетергәндер дип уйладык. Шуннан соң бер тишек күреп алдык та шуны казыдык. Әрлән үз йортын бик катлаулы итеп, барысын да уйлап эшли бит. Бер бүлегендә йоклый, икенчесендә ашый, өченчесендә бала чыгара. Менә шул юкка чыккан ике капчык борчакны әрлән оясыннан табып алдык без. Муен астындагы капчыгына тутырып ташыган ул аны.

Ильяс Фәттахов фикеренчә, соңгы елларда әрләннәр активлашты, дигән сүз дөреслеккә бик үк туры килеп бетми.

– Алар артык азына алмыйлар, чөнки көрәш ысулы җиңел. Әрләнне капкын белән генә дә эләктереп алып була. Шулай ук читлек шикелле тозак эченә берәр яшелчә (мәсәлән, кишер) куеп та җәлеп итеп, эләктерергә мөмкин.

Авыл халкының теңкәсенә тигән, әрләннән яманрак тагын бер җәнлек бар. Анысы – сасы көзән. Әрләннән аермалы буларак, әлеге әрсез һәм усал җәнлек кош-кортларны «ярата».

– Берничә ел элек бездә дә булды андый күңелсез хәл, – ди әңгәмәдәшем. – Яңа Кишет авылында 32 тавыкны буып чыккан иде. Кетәклектә бер әтәч утырып калган… Без малай чакта сасы көзән шулай ук гадәти күренеш иде. Мал-туар, кош-корт күп, шуңа күрә әлеге җәнлекләр дә еш кунак була торган иде. Ул елларда хәтта бүреләргә кадәр төшә иде авылларга.

Бүреләре күренмәсә дә, төлкеләре әле дә очраштыргалый анысы. Дөрес, белгечләр әйтүенчә, быел аларның саны кимегән. Ләкин кайбер авылларда әле дә очратырга, алардан килгән зыянны санарга туры килә.

– Безнең авылда төлкеләр еш кунак була, – ди Балтач районының Арбор авылында яшәүче Руфия Мифтахова. – Йортыбыз авыл читендәрәк урнашкан. Төлкене үзебезнең печәнлектә дә, көтү көткәндә су буенда да күрдек. Күптән түгел генә дүрт тавыгыбыз, бер әтәчебез башы-аягы белән юкка чыкты. Үзебез күрмәсәк тә, шул төлке эшедер дип уйлыйбыз. Авылдашлар арасында да, төлкене, балаларын күрдек, дип әйтүчеләр бар. Быел шактый кешенең кош-кортын алган, дип ишеттем. Үз күзләрем белән күрмәгәч, кистереп кенә әйтә алмыйм. Ләкин халык шулай дип сөйләште. Тавык, каз бәбкәсе, үрдәкләрен кайсын буып, кайсын үзе белән алып чыгып киткән, диләр.

Авыл халкы фикеренчә, хәзер төлкеләрнең дә токымы, холкы алышынган.

– Элекке җәнлекләр түгел инде болар. Сары матур төлкеләр авылга кермиләр иде, – дигән иде бер сөйләшеп утырганда Актаныш районыннан Корбангали Хафизов. – Әтиләр заманында умарталарны урманда тота торган идек. Шунда җәйлеккә тавык, күркәләрне дә алып бара идек. Кош-кортларны тотар өчен сеткалар да юк иде. Лапас кырындагы куначада гына утыралар иде. Шулай булса да, анда төлке килеп, алып китми иде бит. Читкә таралган кош-кортлар гына төлке корбаны була иде. Югыйсә ул вакытта да бар иде алар. Токымнан дип уйлыйм мин аны. Хәзер бит алар песидән аз гына зуррак, җитез. Каралты-курага кош-корт ауларга керсә дә, барысын да буып бетермичә чыгып китми. Аннан соң, элек басуларда салам эскертләре тулып ята торган иде. Тычкан да күп иде, шуңа күрә төлке шунда тамагын туйдырып тик ятты. Анда ризык беткәч, авылга бармыйча кая барсын алар?

Бер айлап тирәсе элек социаль челтәрләрдә ниндидер билгесез җәнлекнең сарайларга кереп, кош-кортларны буып чыккан видеолар таралды. Аларны без республиканың төрле районнарыннан алдык. Татарстанның Биоресурслар буенча дәүләт комитетының хайваннарны һәм үсемлекләр дөньясын саклау идарәсе җитәкчесе Ринат Чиспияков кош-кортларга нинди җәнлек зыян салуын төгәл генә әйтеп бирә алмады. Аның фикеренчә, ул чәшке дә, сасы көзән дә булырга мөмкин.

– Чәшке – ерткыч хайван. Ул су тирәсендә яши, кошларның канын да эчә, итен дә ашый. Ул бер кош белән генә канәгатьләнми, берничәне буып ата ала. Төнлә, тавыклар йоклагач, һөҗүм итә. Кош-кортка сасы көзән дә һөҗүм итәргә мөмкин. Тик чәшкедән аермалы буларак, анысы кырларда яши һәм 1–2 тавык белән дә күңеле була, – ди белгеч.

Кем белән генә аралашсак та, кош-кортларга, йорт җәнлекләренә кыргый этләр һөҗүм итә, дип зарланды. Узган атнада, мәсәлән, шул ук Арчаның Ашытбаш авылында бер хуҗалыкта сукбай этләр унбер йорт куянын харап иткәннәр.

Ахыры 2 нче биттә >

Кермик әле урманнарга

Татарстан урманнарында, шул исәптән Казанда янгын чыгу куркынычы зур булу сәбәпле, табигать афәтеннән кисәтү кертелгән. Гидрометеоүзәктән хәбәр ителгәнчә, кисәтү 5–11 июльдә гамәлдә булачак. Бу чорга төбәктәге янгын куркынычы IV класс дәрәҗәсендә бәяләнә.

Исегезгә төшерәбез: узган елда республикада янгын куркынычы чорында бу афәт 37 миллион сумнан артыграк зыян китергән. 2021 елның 25 апреленнән 15 майга кадәр 1,8 мең янгын очрагы теркәлгән. 34 кеше һәлак булган, 18е зыян күргән.

Халык теләгәнчә

«Безнең ишегалды» программасы буенча эшләр башланганнан бирле «Татарстан шәһәрләрен үстерү институты» фондына 5 меңнән артыграк тәкъдим кергән. Казанда, Чаллы, Әлмәт, Бөгелмә һәм Яшел Үзән районнарында яшәүчеләр бу җәһәттән бигрәк тә зур активлык күрсәткән. Белгечләр әйтүенчә, җирле халыкның тәкъдимнәре ишегалларын чын мәгънәсендә уңайлы, төзек һәм заманча итү мөмкинлеге бирә.

Исегезгә төшерәбез: 23 июньдә ишегалларын төзекләндерүгә сайлап алу буенча тавыш бирү тәгалләнде. Исемлеккә 45 районның 200 ишегалды, шулай ук парк-скверлары, яр буйлары кертелде. Боларның барысы да киләсе елда яңартылачак. Исемлеккә эләккән ишегалларында яшәүчеләр белән быел көзен очрашулар үткәреләчәк. Шулай итеп, алар үзләренең территорияләрен ничегрәк итеп күрергә теләүләрен җиткерәчәк.

Өстәмә ял булмый

Быел Корбан бәйрәме 9 июльдә билгеләп үтелә. Ул шимбәгә туры килә. Ләкин аның өчен өстәмә ял көне бирелми, чөнки закон буенча республика бәйрәмнәре күчерелми. Бу хакта Татарстан Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы матбугат хезмәте хәбәр итә.

Шул ук вакытта җомга – 8 июльдә эш көне озынлыгы 1 сәгатькә кыскара.

Төзүчеләр шаккатыра

Татарстанда шәхси торак төзү буенча быелга ниятләнгән план 73 процентка үтәлгән инде. Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министры урынбасары Динар Сәгъдәтуллин әйтүенчә, быелгы катлаулы шартларда кимендә 2 миллион 75 мең кв. м торак мәйданын төзү күздә тотыла. Шуның 1 миллион 680 мең кв. метры шәхси йортларга туры килергә тиеш. Аның сүзләренә караганда, бездә, шулай ук бөтен Россия күләмендә төзелеш эшләре узган елдагы белән чагыштырганда 40 процентка диярлек алда бара.

2021 елда, төзелеш тармагының ярты гасырлык юбилее елында, торак төзү буенча еллык күрсәткеч арттырып үтәлгән. Татарстан тарихында беренче тапкыр 3 миллион 11 мең кв. м мәйданда торак төзеп тапшырылган. Планда нибары 2 миллион 670 кв. м каралган булса да. Узган елда да шәхси торак төзүгә зур игътибар бирелгән. Гомуми планның 2/3 өлеше шуңа туры килгән.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Яңалык

Кичәге бүгенгә ярамый

Якын киләчәктә юллардан яңа кагыйдәләр буенча йөри башламагаек. Россия Иҗтимагый палатасы вәкилләре хәзерге юл йөрү кагыйдәләре җыентыгын яңадан нәшер итәргә тәкъдим итә. Проект авторлары фикеренчә, 30 ел элек кабул ителгән кагыйдәләрне яңартырга вакыт.

«Юл йөрү кагыйдәләренең хәзерге редакциясе СССР заманында ук әзерләнгән. Андагы кагыйдәләрнең күбесе искерде инде. Шушы вакыт эчендә аңа 50дән артык төзәтмә кертелде. Шуңа күрә бу җыентык хәзер ямалган басманы хәтерләтә. Өсте-өстенә төзәтмәләр керткәнче, аны яңадан язу хәерлерәк», – дип саный проект авторларының берсе, Россия Иҗтимагый палатасының куркынычсызлык комиссиясе рәисе урынбасары Александр Холодов.

Проект авторлары, иң беренче чиратта, соңгы арада телдән төшмәгән электр самокатлары һәм аларга охшаш башка җайланмаларны (гироскутер, моно тәгәрмәч, сигвей) машина белән бер дәрәҗәдәге транспорт чарасы дип танырга тәкъдим итә. Ник дигәндә, быелның биш аенда гына да алар гаебе белән килеп чыккан юл һәлакәтләре саны узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда 35 процентка арткан. Аларда ике кешенең гомере өзелгән, 126 кеше төрле дәрәҗәдәге тән җәрәхәтләре алган. Проект авторларының тәкъдиме чынга аша калса, электр самокатларын да исәпкә куеп, аларга да ОСАГО рәсмиләштерергә туры киләчәк.

Моннан тыш проект авторлары электрон машина йөртү таныклыгын, электрон машина йөртү таныклыгын теркәү белешмәсен дә гамәлгә кертү яклы. Алар тизлек мәсьәләсен дә яңадан карарга тәкъдим итә. Аерым алганда, шәһәр эчендә хәрәкәт итәргә рөхсәт ителгән максималь тизлекне сәгатенә 50 чакрымга кадәр киметү турында фикерләр бар. Билгеле булганча, әлегә бу сан сәгатенә 60 чакрымны тәшкил итә. Моннан тыш белгечләр трассаларда рөхсәт ителгән максималь тизлекне дә хәзерге максималь сәгатенә 130 чакрымнан сәгатенә 150 чакрымга кадәр арттырырга тәкъдим итә. Дөрес, бу очракта түләүле магистральләр турында сүз бара.

Хәтерләсәгез, Россиянең ЮХИДИ идарәсе башлыгы Михаил Черников та журналистлар белән очрашуда шундый тәкъдим белән чыккан иде. «Безнең юллар Европа юлларына караганда да яхшырак. Шуңа күрә аларда хәрәкәт иткәндә җыярга рөхсәт ителгән максималь тизлекне сәгатенә 150 чакрымга кадәр арттырырга мөмкин. Бу очракта юллардагы киеренкелек тә юкка чыгачак», – дигән иде ул чакта Черников.

Сүзгә-сүз

government.ru

Михаил МИШУСТИН, Россия Премьер-министры:

Бик яхшы башкарылган эшләребез бар. Алар, үз чиратында, сәнәгатебезгә бирешмәскә, безгә каршы булучылар фаразлаган драматик хәлләрне булдырмый калырга ярдәм итте. Дөрес, аерым бер тармакларда билгеле бер кимүләр бар, әмма без беркайчан да соң чиккә җитмәдек. Киресенчә, электроника, фармацевтика кебек күп кенә тармакларда үсеш темпы күзәтелә.

(«Иннопром – 2022» халыкара сәнәгать күргәзмәсенең пленар утырышындагы чыгышыннан)

РОССИЯДӘ – ҮЗМӘШГУЛЬЛЕК

«Меркатор» компаниясе Россиядәге үзмәшгульләр санын ачыклаган.

РОССИЯДӘ ТЕРКӘЛГӘН ҮЗМӘШГУЛЬЛӘР САНЫ



2020 елның декабре........................1,5 млн

2021 елның июне.....2,4 млн

2022 елның гыйнвары........................4 млн

58% >> ир-атлар

42% >> хатын-кызлар

Үзмәшгульләрнең уртача яше – 35



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

КАРАКАЛПАКЧА СУВЕРЕНИТЕТ ЯКЛАУ

Дөньякүләм икътисади түнтәрелеш планетаның төрле почмакларында зур фетнә булып кайтаваз бирә. Ачыргыланулы халык күтәрелешләре Һинд – Тын океан төбәгендә, Африкада, Латин Америкасында, Үзәк Азиядә күзәтелә. Тышкы әҗәтләренә бәйле рәвештә дефолт игълан иткән Шри-Ланкада хәл һаман да катлаулы. Анда дәүләт чиновникларына чып-чын ау барды, террор киң җәелеп алды. Илдә нефть һәм нефть продуктлары җитми, чөнки сатып алырга акча юк. Нефтькә бай Ливия – Каддафи идарә иткән чорда мул гына тормышта яшәгән ил – ун елдан артык инде тынычлык таба алмый. Тормыш шартларының начараюыннан туйган халык үткән атна ахырында парламентны яулап алды. Ливия протесты Шри-Ланка юлыннан атлый: дәүләт идарәсендә эшләгән булсаң, ярсудан күзен кан баскан халыкка юлыкмавың хәерле.

Быелның беренче алты ае эчендә Урта Азия инде икенче тапкыр зур тетрәнү кичерде. Бу юлы чират Үзбәкстанга җитте. Табигый байлыкларга үтә бай булган элекке совет республикасы Ислам Кәримов идарә иткән чорда Әндиҗан фаҗигасе белән тарихка кереп калган иде. Кәримов үлеменнән соң илдә берникадәр җепшеклек башланды. Шәүкәт Мирзияев – илнең яңа Президенты – көч структураларының башбаштаклыгын йөгәнли алды, төрмәләр ачылып, сәяси тоткыннар иреккә чыгарылды, башка кайбер уңай үзгәрешләр булды. Идарәсенә алты ел тулып килгәндә, лидер Россия үрнәгендә Конституция референдумы үткәреп, Төп канунга үзгәрешләр кертергә, үзгәртелгән Конституция кабул ителгәч, үзенең президентлык срогын яңабаштан исәпли башларга теләде. Әмма референдумга чыгарылачак үзгәрешләр арасында Каракалпак автономиясен чикли, аның суверенитетын юкка чыгара торганнары да бар иде. Илнең 40 процентка якын территориясен биләп торган, 2 миллионга якын халык яши торган бу төбәк исә гамәлдәге Конституция нигезендә Үзбәкстаннан аерылып чыгу хокукына ия, үзәк белән мөнәсәбәтләрне килешүләр нигезендә көйли ала иде. Бу мөмкинлекләрнең юкка чыгу куркынычы зур ризасызлык уятты. Төбәк башкаласы Нукуста халык урамнарга агылды, Шымбай, Халкабад, Тахтакопир районнарыннан халык төркемнәре башкалага юл алды, юлдагы блок-постларны җимерәләр дигән хәбәрләр таралды. Шәүкәт Мирзияев ашыгыч рәвештә төбәккә килде, чиновникларны: «Ни өчен халыкның риза булмавы хакында миңа шалтыратып әйтмәдегез?» – дип шелтәләде, фетнәгә китергән Конституциянең 70–75 статьяларына кертеләчәк үзгәрешләр туктатылды. Тик шулай да Нукус урамнарында кан коелып өлгерде, диделәр. Газета хәбәрчесе кан белән юылган асфальт төшерелгән фотофактлар алды. Төбәктә бер айга гадәттән тыш хәл кертелде. Бу – шул вакыт эчендә хакимлек көч структуралары кулында булачак дигән сүз. Мәгълүмат кырында, әлеге фетнәне силовиклар Мирзияевка үч итеп оештырдылар, дигән сүзләр дә йөри, гадәттәгечә тышкы көчләрнең кулы уйнавы турында да хәбәрләр таратыла. Әмма без вакыйгаларга бәя бирмибез, фактларны гына китерәбез.

Россиядә

МАУ ФЕНОМЕНЫ

Россиянең эчке тормышында да вазгыять катлаулы. Урта Азиядә барган тектоник үзгәрешләр Мәскәү өчен дә шатлык түгел, чөнки көньяк чикләрдәге гаҗәп зур мәйданнарда йогынты югалу куркынычы тудыра. Төбәк өчен исә Кытай, Төркия, Россия үзара тартышалар, американнар да анда үз мәнфәгатьләре бар дип саный. Каракалпак фетнәсенә Россия катнаша алмый, Казахстан ысулы белән аңа йогынты ясау мөмкинлегенә ия түгел. Бөтен көчләрне көнбатыш чикләрдәге конфликт үзенә тарта. Үткән тәүлекләрдә Россиянең рәсми мәгълүмат кырында (аерым алганда «Российская газета»да) Белгородка украин көчләренең һава һөҗүме ясаулары турында хәбәрләр таратылды. 21 күпфатирлы, 40 шәхси йорт зыян күрде, диделәр, корбаннар да бар. Махсус хәрби операциянең Россия төбәкләренә дә килүе сөендерми, билгеле.

Дөньякүләм кризисның зур чагылышы булган Украина белән конфликт идарәнең югары эшелоннарында да кайтаваз бирә: коррупциягә каршы көрәш тәгәрмәче әйләнә, хыянәтче галимнәрнең илнең технологик серләрен чит илләргә сатулары белән бәйле эшләр кузгатыла. Соңгы көннәрдә Мау эше – Россия Президенты каршындагы Халык хуҗалыгы һәм дәүләт хезмәте академиясе ректоры Владимир Мауның кулга алынуы белән бәйле вакыйгалар зур яңгыраш алды. Мау – бик зур фигура, Ельцин вакытында ук безнең тормышка зур йогынты ясаган, Гайдарга икътисади реформалар рецептлары язышкан һәм соңгы көннәргә кадәр икътисади сәясәткә зур катнашы булган шәхес. Кремль әһелләре белән аралашу мөмкинлегенә ия, аларның киң протекциясеннән файдалана. «Стратегия 2020» дигән, безне ике ел элек үк мул тормышка ирештерергә тиешле программаның төп иҗатчысы. Хөкүмәт подвалларында тау-тау булып өелгән кәгазьләрдә – Россиянең үсеш сызыгын билгеләгән документларда аның кулы уйнаган. Менә шул шәхесне зур күләмдә мошенниклыкта гаепләп, көтмәгәндә кулга алдылар. «Российская газета» аның 2 июльдә Төркиягә чыгып качарга җыенган булуы турында хәбәр итте. Җепнең очы Маудан икенче бер зур галим һәм йогынтлы шәхес, мәгариф министрының элекке урынбасары Марина Раковага карата җинаять эше ачкач килеп ялганган. Тикшерүчеләр аны Ракова белән күзгә-күз очраштыргач, Марина ханым Мауны бик күп җинаятьләрдә гаепләгән, ди рәсми тикшерену материалларына таянып федераль хөкүмәт газетасы. Мауга ташланган гаепләүләр расланса, аның 10 елга кадәр төрмә шулпасы эчәргә шансы бар. Әмма сүз бик зур йогынтылы шәхес турында бара. Кулга алыныр алдыннан гына аны «Газпром»ның Директорлар советына сайладылар. Димәк, җинаять эше ачканда, тикшерүчеләр югарыдагы кабинетлар белән киңәшеп үк өлгермәгәннәрдер дигән фикер дә туа. Нәрсә генә булмасын, Мауга ташланган гаепләү күләме сәгать саен кими. Башта 50 миллион сумлык караклык турында сүз алып барылса, соңга таба урлаган акча күләме Мауның айлык кеременнән дә кимрәк була башлады. 50 миллион сумның да Мау кебек фигура өчен артык зур булмавын искә алырга кирәк. Ректорның судан коры чыгу ихтималлыгы көннән-көн үсә. Улюкаев язмышын, бәлки, кабатламас та. Элекке финанс министры Улюкаев әфәнде исә күптән түгел генә срогыннан алда төрмә сәндрәсен ташлап чыкты. Аны зонадан хөкүмәтнең затлы машиналарыннан торган кортеж алып чыгып китте.

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

КҮПЕРЛӘРНЕ НЫГЫТЫР ЧАК

Нәтиҗәле сәфәр. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның Екатеринбург шәһәренә эшлекле сәфәрен кыскача гына әнә шулай атап булыр иде. Республика җитәкчесе бирегә «Иннопром – 2022» халыкара сәнәгать күргәзмәсендә катнашу өчен килде. Аның кысасында Президент эшлекле очрашуларда катнашты, сессиядә чыгыш ясады.

tatarstan.ru

Юллары билгеле

Иң элек Рөстәм Миңнеханов Екатеринбургта «Иннопром – 2022» халыкара сәнәгать күргәзмәсендә катнашты. Унике ел рәттән уздырылучы күргәзмәнең быелгысы «Сәнәгать көчеше: чакырулардан яңа мөмкинлекләргә» дип исемләнгән иде. Күргәзмәдә Татарстанны КамАЗ, «Татэнерго», «РариТЭК Холдинг», «Химград» кебек эре оешмалар тәкъдим итте.

Сәнәгать күргәзмәсе кысасында Рөстәм Миңнеханов Пермь крае губернаторы Дмитрий Махонин белән очрашты. Очрашуда ике төбәк арасында хезмәттәшлек юллары барланды. «Пермь крае – безнең әйдәп баручы сәүдә-икътисади хезмәттәшләребезнең берсе. Ике төбәк арасында товар әйләнеше 15 млрд сум тәшкил итә. Татарстан тәэмин итү күләмнәрен киңәйтергә тели», – диде Татарстан Президенты.

Рөстәм Миңнеханов, аерым алганда, республиканың машина төзелеше, вертолетлар, авыл хуҗалыгы продукциясе белән тәэмин итү юнәлешендә хезмәттәшлекне көчәйтергә теләвен белдерде. Татарстан Президенты нефть продуктлары базарын, нефть эшкәртү өлкәсендә кооперацияне үстерүне, энергетика өлкәсендә хезмәттәшлек өчен мөһим юнәлешләрнең берсе дип атады. Очрашуда йөк ташу өчен су юлларын үстерү турында да фикер алыштылар. Моннан тыш импортны алыштыру кысасында төбәкләрдәге сәнәгать оешмаларының запас частьлар җитештерү юнәлешендә үзара хезмәттәшлеге турында да сүз булды.

Тагын икәү төзеләчәк

Кечкенә шәһәрләрдә урнашкан кече сәнәгать паркларына активрак ярдәм итәргә кирәк. Рөстәм Миңнеханов Екатеринбургта узган сәнәгать күргәзмәсе кысасында «Җитештерү чылбырларын җыю нокталары – индустриаль парклар һәм махсус икътисади зоналарның сәнәгать көчешендәге роле» сессиясендә чыгыш ясаганда шундый фикер белдерде.

«Татарстанда сәнәгать паркларының резидентларына һәм аккредитацияләнгән республика идарәче оешмаларына салым өстенлекләреннән файдалану, транспорт салымы һәм оешмалар милкенә салым түләү буенча ташламалар алу, электр энергиясе чыгымнарының бер өлешен субсидияләү, инженерлык инфраструктурасы төзелешен финанслау рәвешендә дәүләт ярдәмен куллану мөмкинлеге бирә торган чаралар кабул ителде», – диде Рөстәм Миңнеханов. Татарстан Президенты кабул ителгән чаралар нәтиҗәсендә республикада 96 сәнәгать паркы булдырылуын да искәртте. Бүген аларда 1,5 мең резидент урнаштырылган, 52 меңнән артык эш урыны булдырылган.

Рөстәм Миңнеханов Татарстанда Россиядә иң нәтиҗәле дип табылган ике махсус икътисади зона эшләвен дә искәртте. «Ил Хөкүмәте ярдәме белән «Алабуга» махсус-икътисади зонасы зур нәтиҗәләргә иреште. Узган ел резидентлар табышы 135 млрд сум тәшкил итте. 8 мең эш урыны булдырылды, шәхси инвестицияләр күләме 157 млрд сумнан артып китте», – диде Президент үз чыгышында. – Инвестицион активлыкны арттыру максатында индустриаль парк булдырылды, Россиядә беренче ПАН-прекурсорлар заводы һәм автомобильләр җитештерү буенча «Aurus» заводы файдалануга тапшырылды. 2019 елдан «Алабуга Политех» эшче белгечлекләрен әзерләү үзәге үсә. 2025 елга биредә укучылар саны 10 мең кешегә җитәр дип планлаштырыла».

Рөстәм Миңнеханов Татарстанда «Лаеш» индустриаль паркы белән югары технологияләр өлкәсендә «Иннопарк» технопаркын төзергә җыенулары турында да сөйләде.

Хезмәттәш тә, тугандаш та

«Иннопром – 2022» халыкара сәнәгать күргәзмәсе кысасында Рөстәм Миңнеханов Төркиянең сәнәгать һәм технологияләр министры урынбасары, Төркия Президентының баш киңәшчесе Хәсән Бөекдәдә белән дә очрашты.

Рөстәм Миңнеханов Төркияне Татарстанның әйдәп баручы чит ил хезмәттәшләренең берсе дип атады. Узган ел тышкы сәүдә әйләнеше 563,7 млн доллар тәшкил иткән. Бу 2020 ел белән чагыштырганда 55,8 процентка күбрәк. Быелның беренче кварталында исә товар әйләнеше 142,7 млн доллар тәшкил иткән.

Рөстәм Миңнеханов Татарстан белән Төркия арасында сәүдә-икътисади, инвестицион хезмәттәшлекне үстерүгә зур игътибар бирелүен дә искәртте. Республика белән Төркия Сәнәгать һәм технологияләр министрлыгы арасындагы хезмәттәшлекнең дә югары дәрәҗәдә булуын билгеләп үтте ул. «Безнең өчен бу – аерым министрлык, җитәкчелек һәрвакыт безгә ярдәм итә, Варан әфәнде – безнең дустыбыз. Безнең арада сәүдә-икътисади гына түгел, тугандаш элемтәләр дә бар. Безнең элемтәләрне үстерүгә мөмкин кадәр ярдәм күрсәткәннәре өчен Төркия җитәкчелегенә чын күңелдән рәхмәтлебез. Без Төркия инвесторларына безгә ышанганнары һәм республика территориясендә уңышлы эшләгәннәре өчен рәхмәтле», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Татарстан Президентының фикерен Хәсән Бөекдәдә дә куәтләде. «Татарстан – мөһим сәнәгать төбәге. Мондый очрашулар сезнең төбәккә инвестицияләр артуга ярдәм итәчәк», – диде ул.

Рөстәм Миңнеханов Костанай өлкәсе Хакиме Архимед Мөхәмбәтов белән дә очрашты. Узган ел Татарстан – Казахстан арасында товар әйләнеше 629,6 млн доллар тәшкил иткән. Казахстанга Татарстаннан – пластмасса, нефть, җир өсте транспорты чаралары, каучук, Казахстаннан исә республикага сөт ризыклары, бал, кара металл, электрон машиналар һәм җиһазлар кертелә.

Әрсез кунак

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

– Этләр бик оста бит. Башта читлекнең элгечен борып ачалар. Берничәсе читлек төбендә сакта кала, берсе почмакка барып поскан куяннарны куркытып, куалап китерә. Шуннан соң эләктереп тә алалар, – ди Ильяс Фәттахов.

Белгеч, эколог Наил Назаров әйтүенчә, сасы көзән, төлке һәм башка җәнлекләрнең авылларга төшеп, кош-кортларга һөҗүме – элек-электән күзәтелә торган күренеш. Россиянең урта полосасында урнашкан авылларда әрләннәр дә еш кунак була.

– Авыллар – табигатькә иң якын урын. Анда туклану кимегән очракта, кыргый җәнлекләр авылларга якыная. Мәсәлән, әрләннәр башаклы культураларның авыл хуҗалыгы территорияләрендә мәйданнары кимүе аркасында арта. Азык кимегән саен алар яңа территорияләр эзләргә мәҗбүр була. Моның өчен бакчалар – иң кулае, – ди Наил Назаров.

Аның сүзләренчә, чыннан да, кайбер территорияләрдә теге яки бу җәнлекләр саны үзгәреп тора. Алар кайдадыр кимесә, кайдадыр, киресенчә, артырга мөмкин. Бу да авыл хуҗалыгы культураларының үзгәреп торуы белән бәйле. Якын-тирәдә башаклы культуралар азрак чәчелсә, төлкеләрнең авылларга төшүен көт тә тор.

– Әлеге җәнлекләрнең баш саны һәр районда контрольдә тотыла. Чыннан да, моннан ике-өч ел элек төлкеләр артты. Шунлыктан, аучыларга бүленеп бирелә торган квота күләме арттырылды. Төлкеләрнең саны кимүнең сәбәбе әнә шул, – ди белгеч.

Аның сүзләренә караганда, этләр, мәчеләр булган хуҗалыкларга әлеге җәнлекләр килергә ашкынып тормый.

– Йорт хайваннары саклаган очракта, төлкеләр, сасы көзән, әрлән кебек җәнлекләр бик сирәк очрый. Дөрес, мондый ишегалдына котырган төлке генә керергә мөмкин. Моннан тыш, чакырылмаган кунакларның санын төрле капкыннар да киметә, – ди ул.

КӨН БУШКА ҮТМӘДЕ

Авыл сулышы

«Кырда печән күп икән...» Басу-кырларны урап кайткан һәр авыл кешесе шулай дип сөенә. Шулай булмыйни, үткән ел гына бит, кырга чыксаң, корылыктан, эсселектән көеп утырган яланнарда бер учма печән табуы кыен иде. Алар әле онытылмады. Өстәвенә бу җәйгә сала кешесе бөтен запасын бетереп чыкты. Шуңа күрә печәнне мөмкин кадәр күбрәк тупларга тырыша.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Дөрес, безнең якларда басу-кырларга чыгып, терлегенә кышка печән әзерләүчеләр юк дәрәҗәсендә. Кулында техникасы булган, пенсия яшендә булып, сәламәтлеге мөмкинлек биргән кешеләр санаулы гына. Әле бит чаптың да эш бетте түгел, аны киптерергә, төяп алып кайтырга да буш кешеләр булу кирәк (гадәттә андыйлар кул көче белән, азлап әзерли печәнне). Күпчелек кырларга иртәкич, йә эшкә киткәнче, йә эштән кайткач, малларга көндәлек ашатырга дип чабарга бара. Анысы да бик мөһим. Печәнлеккә кергәне инде кышкы чорга дигән, исәплесанаулы печән, бал ялаган саен кими дигән кебек, көндәлек ашата башлагач, бик тиз кими ул. Шөкер, бүгенгә кадәр малларга ашатырга кайдан гына печән табарга икән дигән уй булмады. Иренмә, бар, чап кына. Шулкадәр муллык! Үткән ел әнә ике бакча печәненең икенче катын малларга чабып ашатырга гына тоттык. Кырда да ашарларына әллә ни печән юк, дидек (әле безнекеләр җәй уртасыннан колхоз болынына керде – аның икенче катын җыймадылар, үзебезнең көтүлек тә шактый иркен, кырка-кимерә торгач, малларга түзмәслек булмады).

Беренче кат басу печәннәрен, ниһаять, чабып-урнаштырып бетергән авыл халкы җиңел сулап куйды. Ни дисәң дә, аларны тыныч кына, рәхәт кенә итеп эшләп, сөенә-сөенә урнаштыра торган булмады. Төннәр салкын булганлыктан, көндезге сүрән кояш кына аларны киптереп бетерә алмады, өстәвенә еш яуган яңгырлар да ашыктырды. Нәтиҗәдә кибәр-кипмәс алып кайткан печәнне печәнлектә генә киптереп бетереп булмады, кызып-бурсып ятканга, көннәр аязгач, кабат җиргә төшереп, киптереп өючеләр шактый күп булды (болай эшләмәүчеләр бик сирәк калды дисәм, дөресрәк булыр).

Бу көннәрдә авылда печән әзерләүнең икенче дулкыны бара. Монысы күпкә җиңелрәк. Халык әзер печәнне урнаштыру белән генә мәшгуль. Кемнәрдер сатып ала, кемнәргәдер хуҗалык өләшә. Халык теленә «процент печәне» дип кереп калган бу печәнне башка елларда бездә инде июнь башында ук, печәнгә төшүгә кайтаралар иде. Быел әлеге дә баягы һава торышы мөмкинлек бирмәде. Авыл халкының күпчелеге «Татарстан» җәмгыятендә эшли, шунлыктан авылда андый печән кайтмый калган йортлар сирәк. «Быел колхоз да беренче каттан печән бирә алмас, көннәре юк, барысын сенажга салырлар инде», – дип курыккан авыл кешеләренең, шөкер, борчылуы тиккә булды. Коры торган көннәрдә чаптырып, киптереп, зур-зур рулонлы болын печәнен һәркемнең капка төбенә кайтарып, елдагыча, сәнәкле тракторлар белән печәнлекләренә үк менгереп бирделәр. Беренче кат печәннән һәр эшләүчегә өчәр рулон исәбеннән өләштеләр. Бер кешегә бишәр центнерлы өч рулон булса, хуҗалыкта дүрт кеше эшләгән авылдашларым Сәйфелганиевларга унике рулон дигән сүз бу (әле Киров өлкәсендә арендага алган печән җирләреннән тагын бер кабат өләшә хуҗалык). Мал-туарны күпләп асрасалар да, шуңа күрә, алар елныңелында каяндыр печән-салам, ашлык эзләп йөрми, әзерләп җәфа да чикми.

Авылда Киров өлкәсе машиналары да еш кунак. Утызар-кырыгар рулон төягән машиналар үтеп тора. Беренче китергәндә уртача зурлыктагы рулоннарны 1250 сумнан сатсалар, хәзер инде алучы, заказ бирүче күп, бәясен 1300 сумга күтәргәннәр. Барыбер кыйммәт түгел, ди үзе печән әзерләп караган кешеләр. Бернинди хезмәтсез капка төбеңә китереп бирәләр, печәнлегеңә менгерергә техника табасы гына кала. «Әллә син үз бакчаңнан чапкан печән очсызга чыга дип беләсеңме? Санап карасаң, безнең рулоннар моннан күпкә кыйммәткә чыга, әле хезмәтеңне кертмичә дә», – ди авылдашым, кировлылар да бәяне күтәргән икән дигән сүземә каршы. Хәер, сәер булса да, хак: печән генә түгел, башка бөтен төр әйберләрне дә, әйтик, сөт-итне җитештерү дә, бәрәңге үстерү дә сатып алганга караганда үз хуҗалыгыңда күпкә кыйммәткә чыга. Санап утырсаң, бөтенләй асрыйсы, үстерәсе түгел кебек килеп чыга. Әмма үземнеке дисең. Хәзер сөт-ит кенә түгел, бер елны Балтачта эшләүче танышым урманнан агач кисеп алып кайтып, агач эшкәртү цехы ачып, эшләтеп җибәргән иде. Әмма бик тиз генә япты ул аны. «Нишләп эшләтмәскә булдың?» – дигәч, «Үзең эшләүнең бер файдасы юк, урманга барып, агач кисәргә кеше таба алмаудан башлап, эшчеләр белән проблемасы күп, икенчедән, бер файдасы калмый. Кировтан әзерне алып кайтып сату күпкә отышлырак», – дип шаккатырган иде. Болары сүз уңаеннан.

Башка елны да бу чорда авылда бөтен эш бергә бөялде, дип зарланыша идек. Быелгыга җитмәгән булган икән әле, дибез хәзер. Соңлаган яз, соңлаган җәй, җылы көннәр көтеп, бер ай өстәмә «кышкы каникул» үзенекен итә. Теге бер айда эшләнергә тиешле эшләр дә бу якка калды шул. Үз чиратындагылары да җитәрлек. Яңгыры-дымы бар, соңгы көннәрдә кояшы да юмартрак. Чүпләр дә сөенә-сөенә үсә, шөкер, бәрәңгеләр дә матур булып күтәрелде. Икенче кат чүпләрдән арындырып, рәт араларын икенче кат эшкәртүчеләр дә (явымлы елны кузгатып, һава кертсәң, әйбәтрәк дип), инде колорадо коңгызына каршы эшкәртүчеләр дә шактый.

Көн бушка үтмәде, шөкер, сау-сәламәт булгач, җан тыныч булгач, шушы кадәр эш эшләнде дип, кичен үз-үзенә хисап бирергә ярата сала кешесе. Юкса белә: иртән күзен ачуга, кабат шушы эшләрнең күбесе көтә үзен. Көтсен, исән-имин эшләргә, яшәргә язсын.

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

ҺӘРКЕМ ТИГЕЗ БУЛСЫН

Гүзәл Садыйкова

Милли мәсьәлә

Имтихан район җитәкчесенең татар теленә мөнәсәбәтен дә чагылдыра. Телне уен рәвешендә дә өйрәнергә мөмкин. Һәр милләт вәкиленә тигез шартлар тудыру өчен тагын ниләр эшләп була? Бу һәм башка мәсьәләләр хакында Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау һәм үстерү мәсьәләләре буенча комиссиянең зона семинар-киңәшмәсендә сөйләштеләр. Бу юлы ул Нурлатта үтте.

Агымдагы елның май аеннан яңа исем астында эшләп килүче комиссиянең эшчәнлеге бүген тагын да киңкырлы, шуңа күрә чираттагы семинар-киңәшмәнең нәкъ менә Нурлатта үтүе аңлашыла. Чөнки районда элек-электән төрле милләт халыклары үзара аңлашып яши. Бүген халыкның күпчелек өлешен (52,8%) татарлар тәшкил итә, икенче урында – чуашлар (25,2%), 21 проценттан артыграгы – руслар һәм 1 проценты – башка милләт вәкилләре. Районда төрле милләтләр арасында татулыкны саклау, аларның үсеше өчен бердәй шартлар тудыру максатыннан эзлекле һәм нәтиҗәле эш алып барыла. Һәм ул балалар бакчалары, белем һәм өстәмә белем бирү учреждениеләреннән үк башлана. Киңәшмә эшендә катнашу өчен республиканың Кама аръягы зонасына караучы 8 районның башлыклары, мәгариф, мәдәният бүлекләре җитәкчеләре аларның кайберләрендә булып, эшнең ничек оештырылуы белән якыннан таныштылар. Башта кунаклар Әхмәдзәки хәзрәт Сафиуллин исемендәге үзәктә булдылар. Биредә дини белем һәм тәрбия бирү белән беррәттән, балаларны татар теленә өйрәтү буенча да эш алып барыла. Мәктәпкәчә һәм мәктәп яшендәге балалар өчен аерым төркемнәр дә булдырылган. Алар үзәктә туган телендә аралаша, милли гореф-гадәтләр белән таныша, кул эшләренә дә өйрәнәләр. «Балаларны үзәккә йөрергә берәү дә мәҗбүр итми. Беренче вакытларда нибары 6 бала килгән булса, бүген – 120», – дип үзәкнең эше белән таныштырды Нурлат районы башлыгы Алмаз Әхмәтшин.

Татар теленнән дәүләт имтиханы күрсәткечләре
Әлки – 28,46 процент
Аксубай – 12,4 процент
Яңа Чишмә – 10,1 процент
Алексеевск – 6,67 процент
Чистай – 1,05 процент

Семинарда катнашучылар шәһәрнең «Кояшкай» татар балалар бакчасында, «Сәләт» сәнгать мәктәбендә дә булдылар. Киңәшмәнең пленар өлеше исә «Киләчәк» балалар иҗаты үзәгендә үтте. Биредә комиссия рәисе Марат Әхмәтовны билингваль студия эше аеруча җәлеп итте. Өстәмә белем бирү педагогы Надежда Алексеева балаларга уен формасында чуаш теле дәресе үткәрде.

Нурлат районында чуаш балаларының 32 проценты үз туган телләрендә белем һәм тәрбия ала. Чуаш теле һәм әдәбияты районның 6 мәктәбендә укытыла, ике авыл балалар бакчасында белем һәм тәрбия бирү шулай ук чуаш телендә алып барыла. Шәһәрдәге ике балалар бакчасында чуаш телле балалар өчен төркемнәр булдырылган, тагын бер төркем ачу планлаштырыла.

Алмаз Әхмәтшин пленар утырышта, районда чуаш халкы актив тормыш алып бара, халык коллективлары эшли, «Дуслык» район газетасы да татар, рус һәм чуаш телләрендә чыга, дип сөйләде. Марат Әхмәтов башка район башлыкларын да, районнарда яшәүче халыкларның саны һәм ихтыяҗыннан чыгып, чуаш, удмурт, мари телләрендә газета чыгару турында уйлап карарга чакырды. «Муниципалитетларның бурычы – республикабызда яшәүче халыкларның телләрен һәм мәдәниятләрен саклау өчен барлык шартларны да тудыру», – дип билгеләп үтте ул, комиссиянең соңгы утырышыннан соң динамиканың берникадәр уңай якка үзгәрүен билгеләп.

Мәктәпләрне уку әсбаплары, җиһазлар белән тәэмин итү, туган телдә белем һәм тәрбия бирүче сыйныфлар санын арттыру, укучыларның телләр буенча олимпиадаларда, төп дәүләт имтиханнарында, укытучыларның грант бәйгеләрендә катнашу буенча активлыклары хакында да фикер алыштылар.

– Укучыларның туган тел буенча дәүләт имтиханнарын сайлаудагы активлыгы – район мәктәпләрендә татар теле укытуның индикаторы, мәгариф бүлеге җитәкчесенең туган телне саклау бурычларына карата мөнәсәбәтенә бәя дә, – диде бу уңайдан комиссия рәисе, Әлки районын үрнәк итеп китереп. Әлеге районда 9 сыйныфны тәмамлаган 123 укучының 35е туган тел буенча имтихан тапшырган. Комиссия рәисе билгеләп узганча, бу – республикада дүртенче күрсәткеч.

Сан

Татарстанда **629** мәктәптә **79673** бала татар телендә белем ала. Моннан тыш, рус телендә белем бирүче **86** мәктәптә татар телендә **278** сыйныф эшли, **364** мәктәпнең **2675** сыйныфында тәрбия татар телендә алып барыла.

Марат Әхмәтов белем бирү учреждениеләре өчен милли кадрлар әзерләү мәсьәләсенә дә аерым игътибар бирергә чакырды. Казан (Идел буе) федераль университетында төрле юнәлешләр буенча белгечләр әзерләнә, студентлар өчен өстенлекле шартлар тудырыла.

Районнарда туган телләрне үстерү һәм саклау буенча эшчәнлек күрсәткечләре Татарстан мәгариф һәм фән министры урынбасары Лилия Әхмәтҗанованың чыгышында конкрет саннар белән күрсәтелде. Аларның һәркайсын район башлыклары каләм очына алды. Марат Әхмәтов Мәгариф министрлыгында төп 10 реаль күрсәткеч буенча муниципаль районнар, белем бирү учреждениеләренең эшчәнлеге рейтингын булдырырга тәкъдим итте. Аның фикеренчә, рейтинг районнарга үзләренең юл карталарын яңадан карап, эш юнәлешләрен дөрес билгеләү өчен кирәк.

Лилия МӨБАРӘКШИНА

ГӨЛЗАДА РУДЕНКО:

«БЕЗГӘ КӨЧ ТУПЛАРГА КИЛӘЛӘР»

Күптән түгел Алабуга дәүләт музей-тыюлыгы генераль директоры Гөлзада РУДЕНКО Россия Президенты Владимир Путин кулыннан Дәүләт бүләген алды. Шул арада Президентны үзләренә чакырырга да өлгергән. Шәһәрнең кайсы урыннарын күрсәтер иде ул аңа? Гомумән, Алабугада туристларны ничек җәлеп итәләр? «Пушкин картасы» яшьләрне тарихи объектлар белән кызыксындыра алганмы? Без шулар турында сөйләштек.

:: 491 гектар саклана торган территория, 184 мәдәни мирас объекты, 17 музей-күргәзмә. Бу байлыкны күреп бетерү өчен гади туристка ничә көн кирәк?

– Бездәге күпсанлы музейлар, экскурсияләр, күргәзмә һәм төрле остаханәләрне ашыкмый гына, иркенләп карап чыгарга теләгән кешегә 2–3 көнгә килергә киңәш итәбез. Ләкин бездә турлар күп, 5 сәгатьтән артмаганнары да бар. Гомумән, экскурсия программаларын туристларның шәһәрдә уздырачак вакытына, аларның кызыксынуларына, яшенә, араларында балалар булу яки булмауга карап оештырабыз.

:: Туристларны һәм шәһәр халкын тагын ни белән шаккатырырга җыенасыз?

– Әле күптән түгел – 21 майда без яңа объект – «Интеллект-үзәк» модулен ачтык. Монда төрле лекцияләр, семинарлар, «түгәрәк өстәл»ләр, квизлар уздырылачак, фильмнар күрсәтеләчәк, «Пушкин картасы» проекты кысасында танылган кешеләр яшьләр белән очрашачак. Узган ел музей-тыюлык составында сирәк коллекцияләрдән тупланган галерея барлыкка килде. Тиздән шушы галереяда Идел буе Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителүгә 1100 ел тулу уңаеннан «Ислам каллиграфиясе дөньясы» күргәзмәсе ачылачак. Гомумән алганда, Күргәзмәләр залы һәм Этносәнгать музее ел саен үзгәреп, кызыклы күргәзмәләр ачылып тора.

:: Туристлар арасында Алабуга музей-тыюлыгының кайсы объекты аеруча популяр?

– Кабатланмас рух саклана торган Шишкин музей-йорты. Монда елына 50 меңнән артык кеше кунак була.

:: Гөлзада Рәкыйповна, соңгы арада илдән чыкмый гына сәяхәт итүчеләр бермә-бер артты. Ил-көндәге вазгыять Алабуганы сайлаучы туристлар санына да йогынты ясадымы?

– Узган ел без 500 меңгә якын турист кабул иттек. Пандемия чоры белән чагыштырганда, ике тапкыр күбрәк дигән сүз. Быел исә бу сан тагын да артыграк булырга охшаган. Россия шәһәрләре буйлап сәфәр чыгучылар саны елдан-ел арта, инде хәзердән туристик агым сизелерлек үзгәрде.

Алабугага килгән һәр турист булырга тиешле 5 УРЫН
✓И.И. Шишкинның музей-йорты (Яр буе урамы, 12 нче йорт)
✓Шайтан каласы (координатлары: 55.746389, 52.0325)
✓В.М. Бехтерев исемендәге өяз медицинасы музее (Нефтьчеләр проспекты, 111А)
✓Н.А. Дурова утар-музее (Мәскәү урамы, 123 нче йорт)
✓Берничә музейны берләштергән М.И. Цветаева Хәтер йорты (Казан урамы, 59 нчы йорт)

visit-tatarstan.com

:: Ничек уйлыйсыз, соңгы 5 елда туристның портреты үзгәрдеме?

– Соңгы елларда безгә килгән туристлар арасында урта һәм яшь буын вәкилләре сизелерлек артты. Туризмның мәдәни-танып белү төрен сайлаучылар арасында гаиләләрнең күп булуы да сөендерә. Аларның балалары яшьтән үк музейлар, гомумән, тарих белән кызыксына, экскурсияләргә йөреп, дөньяны танып белә.

:: «Пушкин картасы»ның ярдәме сизеләме?

– Әлбәттә! Әлеге карта барлыкка килү белән музейларга йөрүче яшьләрнең саны бермә-бер артты. Узган елның сентябреннән «Пушкин картасы» аша 20 меңнән артык билет саттык. Аларның килеп күрүләре – бер хәл. Яшьләрдән бик күп кайтавазлар килде. Безнең эштә бик мөһим нәрсә ул.

«Пушкин картасы» ияләре өчен махсус проектлар да булдырдык. Кызыклы шәхесләр белән очрашулар, махсус экскурсия турлары, остаханәләр. Киләчәктә дә бу өлкәдә актив эшләргә җыенабыз.

:: Алабуга – борынгы шәһәрләрнең берсе. Ул X–XII гасырларда Болгар дәүләтенең төньяк чигендәге ныгытма буларак билгеле. Бу чордан нәрсә дә булса сакланып калганмы?

– Алабуга шәһәрчегендәге манара сакланган. Ул – монголлар яулап алганчыга кадәрге чорга карый торган һәм бүгенгә кадәр сакланган Татарстандагы бердәнбер җир өсте корылмасы. Гомумән, әлеге тарихи-археология комплексы гаҗәеп матур урында урнашкан. Монда экскурсия белән генә түгел, көч һәм уңай энергия тупларга, борынгы ныгытма янында теләк теләргә килүчеләр дә байтак.

:: Күпләр «Шайтан каласы» дип белгән җирләр татар халкына болгар-татар бабалар изге урыны – «Ак мәчет» буларак та таныш. Монда килгән кешеләр тарихның бу бите белән танышамы?

– Әлбәттә. Борынгы болгарлар тарихын экскурсияләр вакытында сөйлибез.

:: Белгәнебезчә, Россия Президенты белән очрашкач, сез аны Алабугага кунакка чакыргансыз. Владимир Путинга нинди маршрут тәкъдим итәр идегез?

– Бездәге музей-күргәзмә объектларын, бигрәк тә Шишкин музей-йортын һәм «Алабуга шәһәрчеге» тарих-археология комплексын күрсәтер идек.

Әңгәмәдәш – Лилия ГЫЙМАЗОВА

Язучы фикере

Марат КӘБИРОВ

Үземнең файдам күпме икән?

Мин бакчада чүпләр утап йөрим. Чүп үлән шулхәтле уңган. Суган арасында чүп, кишер арасында чүп. Түтәл белән түтәл арасында да – чүп. Илдә – төрле афәт, бакчада – чүп. Икесеннән дә котылырлык түгел.

Койма буйларыннан кычыткан утыйм. И чага… Быел ул бөеклекнең чигенә җитеп үсте. Гәүдәсе дә олы, чагуы да, агуы да хәтәр.

– И кычыткан, нигә шундый зур син, нигә шундый күп син? – дип тиргим тегене. Ул эндәшми. Чага торган нәрсәләр гел шулай була ул, дәшми-тынмый гына чага.

Кычытканы – койма буйларында гына. Бөтен җирне сары чәчкә басты. Тузганак дип атала икән ул. Бар дөньяны басып алмаса, исемен дә белмәс идем әле. Басты. Тузганак булган җирдә бернәрсә дә үсә алмый икән. Үсмәсен дә, бүтән бернәрсә дә кирәк түгел.

Ул булмаган җирдә алабута үсә. Алабутасы да җайлы түгел. Бөтен җирне басып ала торган. Бүген утап бетердем дип уйлыйсың, ә ул иртәгә тагын калкып чыга да мыскыл иткән сыман күкрәген киереп утыра. Тагын бар дөньяңны басып ала. Син утыйсың…

Кайчагында сүгенә-сүгенә алып ыргытасың. Шушы хәтле чүп булырга тиеш түгел бит инде бу дөньяда, дип уйлыйсың. Тик дөньяда чүп бар. Һәм син аны мәңгегә дә утап бетерә алмас кебексең…

Син чүп дип чүпләп йөргән нәрсәләрне мактыйлар да бит әле ул. Менә тузганак чәчәкләреннән бал ясыйлар икән. Шәраб ясыйлар. Шул шәраблар турында язып классик булалар. Аның тамыры да, сабагы да, яфраклары да файдалы, ди. Бөтен дөньяны басып алган шул тузганакның бөтен нәрсәсе дә файдалы икән. Тик без аны аңларга теләмибез. Ул шулкадәрле күп булгач, кадерсез булып тоела. Без файдалы нәрсәләрнең аз булганын яратабыз. И, аз булса, әллә кайлардан эзләп алыр идек әле. Урманнарга барып җыяр идек. Ә күп булгач, бар дип тә белмибез. Күп булып үскән нәрсә юк кебек.

И, ул кычыткан… Чагып җаныңны айкаса да, койма буйларында ямьсез булып үссә дә, аның да файдасы күп икән бит. Әллә нинди чирләргә дәва икән ул. Ризык та икән әле. Ачлык елларда кешеләр шул кычытканнан аш пешереп адәм булганнар икән. Бүген дә пешерәбез инде аның ашын. Кызык өчен генә. Өстәлне төрләндерү өчен. Ә теге вакытларда ул яшәү көче булган.

Ә алабута… Аннан хәтта икмәк пешергәннәр… Ачлыктан йончыган кешеләрне шул алабута үлемнән алып калган. Адәм баласының тамагы туйса, үзен ач үлемнән коткарып калган нәрсәләр дә чүп булып күренә икән.

Мин бакчада чүп утап йөрим… Тузганакларны… Кычытканнарны кырам… Алабуталарны алып атам…

Мин – кеше. Мин үземне туган җиремдә дип уйлыйм. Хуҗа дип. Бу җирдә мин теләгән нәрсәләр генә үсәргә тиеш дип уйлыйм. Мин теләмәгән нәрсәләр үсмәскә тиеш дип уйлыйм.

Ә бит без гел шундый… Үзебез күрергә теләгәннәрне генә күрәбез, үзебез үстерергә теләгәннәрне үстерәбез. Үзебез күрергә теләмәгәннәр чүп булып күренә. Аларны йолкып алабыз. Без гомер буена, чүпләр йолкып, чәчәкләр үстереп йөрибез. Кайчагында бер чәчәкне үстерү өчен икенче чәчәкнең гомерен өзәбез.

Мин бакчада чүпләр утап йөрим.

Алар быел уңган. Алар күпләр. Мин үземнең туган җирдә кебек. Бу бит – аларның да туган җире. Мин нәкъ шушы чүпләр ватанында яшим. Чүпләр утап йөрим… Ә алар адәм баласын дәвалый да, үлемнән дә алып кала.

Мин шул үләннәрнең файдасы күплеген беләм.

Ә үземнең файдам күпме икән?

Кайсыбыз чүп икән?

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

ТАИФ компанияләре төркеме коллективы, «ТАИФ» акционерлык җәмгыятенең икътисади иминлек, сак һәм режим идарәсе әйдәп баручы белгече **ЮСИПОВ Линар Аббас улы** вафат булу сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

Белдерү

Татарстан Республикасының «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе» дәүләт бюджет учреждениесе, Татарстан Республикасы Сайлау кодексы нигезендә, 7 нче Ибраһимов бер мандатлы сайлау округы, 14 нче Пионер бер мандатлы сайлау округы буенча алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын өстәмә сайлау максатында, 2022 елның 13 августыннан 2022 елның 9 сентябренә кадәрге чорда сайлау алды агитациясе үткәрү өчен, «Ватаным Татарстан» газетасында (массакүләм мәгълүмат чарасын теркәү турында таныклык 1995 елның 21 июнендә бирелгән, № 430) басма мәйдан бирергә әзер булуы турында хәбәр итә.

Сайлау алды агитациясе үткәрү өчен бушлай бирелә торган басма мәйдан күләме һәр кандидатка 6,2 х 7,5 кв. см үлчәмендәге модульне тәшкил итә.

Басма мәйдан бирүгә жирәбә үткәрүнең анықланган вакыты, шулай ук агитация язмаларының календарь графигы турында өстәмә хәбәр ителәчәк.

Белешмәләр алу өчен телефоннар: 8 (843) 222-09-65, 222-09-70. Электрон почта адресы: info@vatantat.ru.

Татарстан Республикасының «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе» дәүләт бюджет учреждениесе, Татарстан Республикасы Сайлау кодексы нигезендә, 7 нче Ибраһимов бер мандатлы сайлау округы, 14 нче Пионер бер мандатлы сайлау округы буенча алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын өстәмә сайлау максатында, 2022 елның 13 августыннан 2022 елның 9 сентябренә кадәрге чорда сайлау алды агитациясе үткәрү өчен, «Ватаным Татарстан» газетасында (массакүләм мәгълүмат чарасын теркәү турында таныклык 1995 елның 21 июнендә бирелгән, № 430) басма мәйдан бирергә әзер булуы турында хәбәр итә.

Сайлау алды агитациясе үткәрү өчен түләүле нигездә биреләчәк басма мәйдан күләме һәр кандидатка 6,2 х 7,5 кв. см үлчәмендәге модульне тәшкил итә.

Түләүле басма мәйдан бәясе А2 форматындагы чыгарылышта (беренче биттән тыш) – 1 кв. см өчен 95,04 сум, А3 форматындагы чыгарылышта (беренче полосадан тыш) 1 кв. см өчен 171,72 сум тәшкил итә.

Беренче полосада урнаштырган өчен – төп бәягә 20 процент, полосада урын сайлап алган өчен төп бәягә 10 процент өстәп түләнелә.

Газета редакциясе түләүле басма мәйданны бүлү буенча жирәбә үткәрү урыны һәм вакыты турында өстәмә хәбәр итәчәк.

president.tatarstan.ru/

Свердловск

Свердловск өлкәсендә Сабан туе 2005 елдан бирле үткәрелә. Быел ул 15 нче мәртәбә үтте. Милли бәйрәмдә Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов һәм Свердловск өлкәсе губернаторы Евгений Куйвашев катнашты.

Мәгълүм булганча, Свердловск өлкәсендә 143 мең 803 татар яши. Рәсми рәвештә 10 татар иҗтимагый оешмасы теркәлгән. Җиде татар якшәмбе мәктәбе эшли, ә 18 гомуми белем бирү мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты фән буларак укытыла. Төбәктә 74 татар һәвәскәр иҗат коллективы бар. Свердловск өлкәсе халкы Татарстанның халык шагыйрьләре һәм язучылары белән даими очрашулар үткәрә.

«Татар халкы өчен Сабантуй – иң яраткан бәйрәмнәрнең берсе. Свердловск өлкәсе губернаторына, төбәк Хөкүмәтенә бу чараны бик яхшы оештырган өчен рәхмәт белдерәсем килә. Гомумән, татар милли-мәдәни оешмаларының инициативаларын хуплаганы өчен», – диде ТР Президенты, сәламләү сүзе белән мөрәҗәгать итеп.

Өлкә Сабан туе 2005 елдан бирле төрле муниципаль берәмлекләрдә үткәрелә, соңгы 8 елда даими үткәрү урыны – Сысерт шәһәр округының Кадниково авылы.

БӨТЕНЛЕГЕБЕЗ – ТӨРЛЕЛЕКТӘ

Мордовия, Аксөн

Сабан туйларының шактыен күрдек, мондыен беренче мәртәбәдер. Хәтта Татарстан Президенты да бит: «Үткәрү масштабы буенча Казан белән ярышырлык», – дип бәя бирде Мордовиянең Ләмбрә районындагы Аксөн авылында узган XII Бөтенроссия авыл Сабан туена. 84 гектар мәйданга урнашкан көрәшле, этноутарлы, җырлы-биюле, сый-хөрмәтле милли бәйрәмдә «ВТ» хәбәрчесе дә булып кайтты.

president.tatarstan.ru/

Дуслык ишегалды

Сабан туе эчендәге Сабантуйны күргәнегез бармы икән? Аксөндә исә бу мөмкин хәл иде. Сабан туе мәйданчыгында Мордовиянең төрле районнары үз ишегалларын тәкъдим итте. Һәркайсының сөйләргә, күрсәтергә, тәкъдим итәргә, сыйларга үзләренә генә хас нәрсәләре дә бар бит әле! Кунакларны мордва, татар көйләре каршы ала, бәйрәмнең буеннан буена озата йөри. Әле өйләренә таралгач та, күңелләрендә көй булып яңгырарлык булды ул.

Милли утарлар буенча атлыйбыз. Мордовиянең Атюрьево районы утары бодай коймагыннан авыз итәргә кыстый. Ризыкның тарихи ватаны шушы икән. «Иң күңелле җырлар да бездә генә!» – дип, җыр-биюгә әйдәп торды утарда каршы алып торучы апалар.

Инсар районы да кимен куймый. Коймакны да күпләп, башка камыр ризыкларын да мулдан пешереп килгәннәр. Милли киемнәре, курчаклары, уен коралларын да онытмаганнар. Моңа өстәп иң чиста сулы чишмәдән су белән сыйларга, кыр үләннәреннән чәй эчерергә чакырып торалар. Балчылык белән бик дуслар икән. Кукмара итеге белән дан тоткан кебек, алар да итекләре белән мактана ала икән. Кул остасы Татьяна Байчурина, эссе булуга карамастан, бәйрәм кунаклары итек алмый китмәс, дип ышанып утыра иде.

Торбеево районы татар һәм мордва халык ризыкларын, «күңелле хәсрәтләнү» (моң-зарны да җырлап, елмаеп кабул итүләре инде) җырларын алып килгән. Йоклап ята торган халык түгелләр икән: иртәнге 4тән үк торып, мәйданга килеп җиткәннәр. Башкалардан калышып буламы соң?!

– Сәнәгать тә үсеш алган, кирпеч сугу, май заводы да бар районыбызда. Авылларыбыз да нык, – дип таныштыра Дубенск районындагы Поводимово авылыннан Антонина Салаева. Салада клуб мөдире булып эшли икән. – Авылыбыз бик матур. 2 мең кеше яши. Халкыбыз бик тырыш. Кулларыннан эш килә. Барысын да эшлиләр. Мәдәниятне, телне, традицияләрне саклау кыен түгел ул, сеңлем! Кызыксыну кирәк. Без клубта фольклор ансамблен оештырдык. Борынгы эрзя халык җырларын башкарабыз. Аларны эзлибез, туплыйбыз. Әле шушы көннәрдә генә Саранскидан студентлар килеп китте. Авыл буенча борынгы җырларны барлап йөрдек.

Милли ризыклары кишер уылдыгы һәм каймак икән. Соңгысын сөт ризыгы белән бутарга ашыкмагыз. Безнең дучмакка охшап тора, бәрәңге пирогын хәтерләтә.

Данлыклы Ләмбрә районы исә тарихи утар тәкъдим итте. Биредә мичтә икмәк тә пешерделәр, печәнгә дә төштеләр, утын да ваттылар, кер дә юдылар, умарта да карадылар.

Мордовиянең атказанган мәдәният хезмәткәре Гүзәл Казакова районның тарихы белән таныштыра. Татарларның нинди тырыш булуларын күрсәтер өчен ныклап әзерләндек, ди. ТАССРдан читтә булган беренче татар районында яшибез – Ләмбрә халкы әнә шуның белән горурлана икән. Гүзәл ханымны Сабан туе кунаклары кызыксындырган сораулары белән әле бер генә мәртәбә аптыратмады бу көнне.

Татарстанны исә, традиция буенча, Кукмара районы тәкъдим итте. Район башлыгы Сергей Димитриевка: «Республиканы бөтен зур Сабантуйларда тәкъдим итеп йөреп армадыгызмы соң?» – дип төрттердек тә әле.

Татарстанның Зәй районындагы Аксар авылы турында: «Аксарлар төн йокламый», – дип әйтәләр бит әле. Менә Аксөннәр дә шундыйлардан. Нык, төпле, куллары хезмәт белгән, кәсеп итә белгән авыл бу. Үз эшләре белән шөгыльләнүчеләре күп. Үзләре җитештергәнне үзләре ашый да, сата да. Аксөн җирлегендә 1559 кеше яши. Төп халкы – татарлар. Мордовиядә 43 мең татар гомер кичерә.

– Юк! Безнең районыбыз өчен бәхет кенә ул! Мин гел шулай дим. Безнең район авыл хуҗалыгы тармагы алга киткән җирлек саналса да, сәнәгать өлкәсе дә артта калмый. Шуларны күрсәтү өчен бер мөмкинлек тә бу, үзенә күрә реклама, – дип җаваплады Кукмара башлыгы. – Уңышларыбыз да бар бит. 400 тонна сөт җыйдык. Республикабызны шаккатырдык. Авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре ирешкән уңышларында туктап калмый, чикләр юк. Саулык-сәламәтлек булсын, без әле 500гә җитәчәкбез. Президент та безгә бүген яхшы бәя бирде. Елдан-ел остарабыз, мондый бәйрәмнәр булып торганда, үсешкә мөмкинлекләр җитәрлек.

Соңрак исә безгә сер итеп кенә шуны да әйттеләр: Рөстәм Миңнеханов Кукмара утарын игътибарсыз калдырмаган. Әйтми-нитми генә кереп чыккан ул аларга. «Әзерләнеп тормасыннар, ә һәрвакыт әзер булсыннар!» – дигән ди ул. Кукмаралылар исә сынатмый инде ул яктан.

Чыннан да, Кукмара итегенә, савыт-сабасына кызыксыну җитәрлек булды бу көнне. Мордовия хуҗабикәләре дә үзебездә җитештерелгән аш-су товарларыннан канәгать калыр дигән өметтә калыйк.

Матур кешеләр ясаган матур бәйрәм

Аксен Сабан туенда Россиянең 24 төбәгеннән делегация килде, меңәрләгән кеше кунак булды. Иң зур делегация – Татарстаннан.

Сабан туе мәйданчыкларын йөреп чыкканнан соң, бәйрәмне рәсми төстә ачып, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов котлау сүзләрен җиткерде.

– Сабантуй – матур бәйрәм. Бүген аны илебезнең 58 төбәгендә һәм дөньяның 35 илендә бәйрәм итәләр. Мордовиядәге бәйрәмне оештыручыларга рәхмәт. Урыны да, бәйрәме дә, иң мөһиме – кешеләре дә искиткеч, – диде ул.

Мордовия башлыгы Артем Здунов исә бу көнне республика өчен бәхетле көн дип атады.

– Россия Президенты 2022 елны илнең мәдәни мирасы елы дип игълан итте, быел без Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулуны бәйрәм итәбез, һәм нәкъ менә быел безгә Бөтенроссия авыл Сабан туен уздырырга ышанып тапшырдылар. Сабантуй – бик күңелле бәйрәм. Тырышып эшләгәч, ял да итәргә кирәк. Мондый бәйрәмнәр безнең берләшү, дуслашу бәйрәме дә әле, – диде республика башлыгы.

Киләсе Бөтенроссия авыл Сабан туе исә Әстерхан өлкәсендә узачак. Мордовия башлыгы бәйрәмнең символы – «Тулпар ат»ны Әстерхан өлкәсе хакимияте башлыгы Павел Паутовка тапшырды.

Машина да, тәкә дә, ял да Раилгә!

Кемдер җыр тыңлаган, кайсылары кунакчыл республиканың сыйларыннан авыз иткән арада, мәйданда пәһлеваннар бил алышты. Көне дә, көрәше дә кызу булды. Көч сынашырга Россиянең 25 төбәгеннән йөзгә якын көрәшче килгән иде. Алар 8 төрле авырлык категориясендә бил алышты.

Безнең игътибарлы күзләр, әлбәттә, Татарстан пәһлеваннарына төбәлде. Безнеке генә түгел, Мордовия тамашачысының да. Әнә бит түбәтәйле абзыйлар да: «Татарстан егетләреме бу? Алар көрәшә белә инде! Алар көрәштә «списиәлист»!» – дип мактап утырдылар.

Көрәш финалына 16 көрәшче чыкты. Төп приз өчен исә ике Татарстан батыры – барыбыз да белгән егетләр Раил Нургалиев һәм Булат Мусин көрәште. Хәлиткеч ярышка Булат – 100 кг авырлыктагы категориядә җиңүче буларак, ә Раил абсолют категориядәге җиңүче буларак чыкты.

Сабан туе турында фикерләр

Айдар ФӘЙЗРАХМАНОВ, Татар дәүләт филармониясенең һәм Татарстан дәүләт фольклор музыкасы ансамбленең сәнгать җитәкчесе:
– Бөтен нәрсә хәрәкәттә, үзгәрә, камилләшә. Әмма нигезебез – миллилек, татарлык сакланып калырга тиеш. Сабан туе белән дә шулай. Заманасы белән, мөмкинлекләре дә арта. Әмма исемендәге асылы кала. Сабан эшләре беткәч бәйрәм итү ул. Ә без төрлечә бәйрәм итәбез! Кемдер җырлый, кемдер бии. Сабантуйларны бөтен Россия, дөнья күләмендә үткәрәләр. Бу бит – татар халкын таныту дигән сүз дә. Сабан туенда без үзебезне күрсәтәбез. Хәтта үзебездә җитештерелгән машиналарга, милли кухнябызга кадәр бит! «Нәрсәгә шулкадәр акча тотып бәйрәм ясарга?» – диләр инде. Акча ул – кәгазь. Без үз бәйрәмебезне башка милләтләр белән кушылып үткәрә алабыз икән, матур күренеш бит. Без татарлыгыбызны сәнәгатебез, сәнгатебез белән күрсәтергә тиеш.

Рушан РАМАЗАНОВ, Бөтенроссия билбау көрәше федерациясе президенты:
– Мордовиядәге Сабан туе бик югары дәрәҗәдә оештырылган. Лаеклы бәйрәм! Бу татарлар өчен генә бәйрәм түгел. Ул барлык мәдәниятләрне берләштерә. Утарларны карaганда да күпме мәгълүмат белән танышасың. Оештыру яхшы булгач, халыкның да кәефе күтәренке.

Сүз уңаеннан, җиңүчеләр арасында дүрт кеше – Татарстаннан, икәү – Чувашиядән, берешәр кеше Мордовия һәм Ярославль өлкәсеннән булды.

Ике төрле авырлыктагы көрәшчеләрнең мәйдан бүлешүенә гаҗәпкә калырга кирәкми. Россия Көрәш федерациясе башкарма директоры Ришат Мөбарәкҗанов аңлатканча, бу спорт төрендә андый очраклар булып тора. Хәтта авырлыгы түбәнрәк булганнарның да «зуррак» иптәшләрен җиңүләре дә юк түгел.

Бу юлы алай булмады шул. Бил алышуда Раил Нургалиев өстен чыкты. Аңа Татарстан Президенты бүләгән – «Лада» машинасы ачкычын тапшырдылар. Моннан тыш Раилгә тәкә һәм Сочига ике атналык юллама да бүләк иттеләр. Соңгысы исә – танылган батыр Хәбил Бикташев «күчтәнәче».

«ВТ» хәбәрчесе Раил белән көрәш ярышыннан соң сөйләшеп алды.

– Шундый матур Сабан туе булды, бик яхшы оештырылган, – диде көрәшче, хисләрен тыя алмыйча. – Көрәшчеләр Татарстаннан гына түгел, башка төбәкләрдән дә килгән. Көрәшү авыр булды. Күреп тордыгыз: Чаллы батыры белән беренче ярышта 1 сәгать көрәштек!

Көрәшнең гаделлеге турында да сораштык.

– Әлбәттә! Барысы да көрәште. Гадел, чиста көрәш барды, – диде Раил.

Булат Мусинның да кәефен сораштык.

– Барысы да яхшы. Үземнең авырлыктагы көндәшләрем дә артык кыенлык тудырды димәс идем. Финалда бераз читенрәк булды инде. Раил – әйбәт көрәшче, – диде ул безгә. – Аз-маз җәрәхәтләрем дә бар иде. Үземә дә куркыныч тудырмаслык итеп көрәшеп чыктым, шуңа канәгать.

Сабан туеның тагын бер мөһим ярышы – ат чабышы турында да онытмыйк. Биредә дә кызу көрәш барды. Мордовия башлыгы призына ат чабышының финал узышында Чувашия, Татарстан, Пенза өлкәсе, Мордовия командалары катнашты. 1600 метрга узышта Илсур Галимҗанов җиңде. Җайдак сүзләренчә, узыш җиңелләрдән булмаган. Әмма җиңүне аты үзе китергән, аңа рәхмәт, ди. Илсурга кубок һәм машина ачкычы тапшырылды.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Мәскәү

Пандемияле ике елда халык Сабан туен сагынды. Гаиләләрне, берничә буынны зур мәйданга җыя ул. Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, мәскәүлеләрне Сабан туе белән котлап, шулай диде. Бәйрәм узган шимбәдә Мәскәүнең тарихи, иң гүзәл урыннарыннан берсе – «Коломенское» музей-тыюлыгында гөрләде. Аңа илнең төрле почмакларыннан 250 меңнән артыграк кеше җыелды.

Барча халыкны бәйрәм белән Татарстан җитәкчелеге исеменнән Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин тәбрикләде.
– Сабан туе – борынгыдан килгән бәйрәм. Баштан ук авыл хезмәтенә, хезмәтчәннәренә ихтирам йөзеннән, «сабан бәйрәме» буларак билгеләп үтелгән, – дип искәртте Фәрит Мөхәммәтшин. Хәзер аны шәһәрдә дә, авылда да бәйрәм итәләр. Мәйданга төрле милләт вәкилләренең җыелуы безне бик нык сөендерә. Сабан туе илебездә яшәүче барлык халыклар өчен күпмилләтле бәйрәмгә әйләнде.

Дәүләт Советы Рәисе басым ясап әйткәнчә, Сабан туе быел Россиянең 56 субъектында һәм дөньяның 34 илендә бәйрәм ителә.

– Сабан туе ил буйлап атлый, – дип билгеләп үтте Мәскәү шәһәр Думасы Рәисе Алексей Шапошников. – Мәскәү Сабан туе төбәкләрдәге бәйрәмне төгәлли. Әмма без йомгак ясамыйбыз, бәлки 2023 елгы Сабантуйга старт бирәбез. Россиядә 197 милләт вәкиле яши. Бердәм булганда, безне беркем җиңә алмаячак!

Бәйрәм кунаклары өчен бик матур тамаша оештырылды. Иртәдән үк мәйданда татар, башкорт җырлары яңгырады, төп мәйданда милли иҗат коллективлары чыгыш ясады. Ә инде көрәш, гадәттәгечә, иң күп тамашачыны җыйды.

Мәйдан үзәгендә узган гасырның көнкүрешен чагылдырган татар һәм башкорт «авыл»лары үзенә җәлеп итеп торды. Биредә милли сувенирлар, халык кәсебе әйберләре белән сату оештырылды, татарларның телеңне йотарлык чәкчәге, башкортларның хуш исле балы, милли аш-сулар кунакларны әсир итте.

Мәскәү мөселманнарының Диния нәзарәте мәйданчыгы китап сүзенә сусаучыларны үз тирәсенә җыйды. Ачык һавадагы «китапханә»дә яраткан әсәрләрне уку гына түгел, бәлки әле китап авторлары белән аралашу мөмкинлеге дә ачылды. Сабантуй мәйданчыкларында көне буе «Мөселман халыклары һәм хакимнәре» дигән күргәзмә эшләде. Сабантуй кунаклары «Игелекле күршеләр урамы» милли чатырлары аллеясында төрле бәйгеләр һәм мастер-классларда катнашты, ат спорты ярышларын карады.

Тарихына күз салсак, болайрак. Сабан туе Мәскәүдә узган гасырның 30 нчы елларында билгеләп үтелә башлаган. Башта аны «Нескучный сад»та бәйрәм иткәннәр, ләкин бик күп вакыт дәвамында онытып торганнар. Бәйрәм 1989 елда гына яңартылды. Әмма бәйрәм урыны берничә тапкыр үзгәртелде. Сабан туе быел «Коломенское»да унынчы тапкыр уздырылды.

Тормыш бишеге

Баулы

Язгы кыр эшләре тәгәлләнеп, печән өсте башланганчы, удмурт халкы рәхәтләнеп бер күңел ача. Баулы районының Кит-Озеро авылында удмурт халкының Гырон быдтон бәйрәме гөрләде. Татарстанда бу бәйрәмне 1998 елдан бирле зурлап оештыралар. Тәүге тапкыр да ул нәкъ менә Баулы җирендә узды.

Быел баулылар бәйрәм кунакларын тәмле ризыклар, дәртле биюләр һәм традицион «ручеек» уены белән каршы алды. Бәйрәм хуҗалары сый-хөрмәтне дә мулдан хәзерләгән иде: удмурт халкының традицион ризыклары – итле перепеч, «зырет» соусы белән белен, бәрәңге һәм эремчекле ризыкларыннан теләгән һәркем авыз итә алды.

Болын-кырларда үсүче үләннәрнең шифасы һәм зыяны турында күбрәк белергә теләүчеләр исә махсус чатырга рәхим итте. Монда чәен дә эчерделәр, каен себеркесе дә ясарга өйрәттеләр, үләннәр белән дәвалану серләрен дә сөйләделәр.

Бәйрәм кеше тормышының төрле чорлары турында хикәяләүдән, «Улон какы» («Тормыш бишеге») дип аталган кереш өлештән башланып китте. Композиция Баулыда яшәүче удмуртлар фольклорына, аерым алганда, сабыйларны йоклата торган бишек җырларына һәм төрле стихияләрнең Аллалары белән таныштыруга нигезләнгән иде.

Татарстан Премьер-министры урынбасары Ләйлә Фазлыева район данын күтәрүче Баулы ветераннарына һәм удмурт мәдәниятенә игътибарлы мөнәсәбәтләре өчен удмурт автономиясенә рәхмәт белдерде.

Баулы районы администрациясе башлыгы Ильяс Гозәеров сүзләренчә, мондый бәйрәмнәр үткәрү мәдәни мирасны саклау һәм Татарстан халыкларының милли үзенчәлеген үстерү максатыннан уздырыла. «Алар үсеп килүче буында үз халкының гореф-гадәтләренә карата ихтирам-хөрмәт тәрбияли. Бүгенге Гырон быдтон да, нәкъ 24 ел элеккегесе кебек, сезгә яхшы хис-кичерешләр бүләк итәр дип ышанам», – диде ул.

Бәйрәмдә катнашучыларны Удмуртия Республикасының Малопурга районы Бураново авылыннан килгән данлыклы «Бураново әбиләре» («Бурановские бабушки») фольклор коллективы да битараф калдырмады. Алар белән фотосурәт ясау өчен шактый озын чират тезелгән иде.

Гырон быдтон узган мәйданда алты кечкенә мәйданчык әзерләгәннәр иде. Кунаклар татар, рус, чуаш һәм удмурт халыкларының мәдәнияте һәм көнкүреше белән танышты. Ә кич белән Покровский-Урыстамак авылы мәдәният йорты каршында удмурт эстрадасы артистлары һәм Казаннан килгән «Zakaria» фольклор төркеме чыгыш ясады.

Бу бәйрәмнең тагын бер үзенчәлеге бар: Гырон быдтон кунакларын ел да бер район кабул итә. Чөнки һәр җирлекнең үзенә генә хас традицияләре була. Шулай итеп, киләсе бәйрәм Кукмара районында узачак.

Мария КАНДАУРОВА

bavly-tat.ru

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 6640 данә
Гомуми тираж – 16041 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 294

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+